[Яр Чаллы шәһәренең әдәби тормышы яңалыклары] // Мәйдан. – 2025. - №1. – Б. 160.

**17 декабрь көнне** Яр Чаллыда әдәбият көне узды. Бер төркем язучылар – Ркаил Зәйдулла, Факил Сафин, Рәзинә Мөхияр Газинур Морат, Рифә Рахман, Айрат Суфиянов, Зиннур Мансуров, Йолдыз Шәрәпова, Лилия Гыйбадуллина, Илфак Ибраһимов, Айгөл Әхмәтгалиева, Булат Сәлахов, Габдулла Вафин, Галимжан Гыйльманов, Рафис Корбан, Әлфия Ситдыйкова шәһәрнең төрле мәктәпләрендә, укучы балалар белән очрашуларда катнашып, чыгышлар ясадылар.



**26 декабрь көнне** ТР Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлегендә еллык йомгаклау җыелышы узды. Чарада Яр Чаллыда, Актаныш, Мамадыш, Түбән Кама, Алабуга һ.б. төбәкләредә яшәп иҗат итүче язучылар катнашты. Каләм әһелләрен Яр Чаллы Башкарма комитеты мәдәният бүлеге җитәкчесе Румил Кәрәмиев сәламләде. Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге җитәкчесе – язучы Факил Сафин бүлекнең еллык эшчәнлеге турында чыгыш ясады. ТР Халык рәссамы Мәдияр Хаҗиев бүлеккә үзе иҗат иткән картиналарны – Гаяз Исхакый, Дәрдемәнд портретларын бүләк итте.



